| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>БОЛЬШЕТИГАНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>ЗУР ТИГӘНӘЛЕ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

22.03.2019 Зур Тигәнәле авылы № 122

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Зур Тигәнәле авыл җирлегендә**
**муниципаль хезмәт турындагы**
**Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Алексеевск районы прокуратурасының 30 гыйнвар, 2019 ел, 02-08-02 нче гаризасын үтәү йөзеннән, шулай ук гамәлдәге законнарга, шул исәптән "Коррупциягә каршы көрәшү турында"гы 25 декабрь, 2008 ел, 273-ФЗ санлы Федераль закон нигезләмәләренә туры китерү максатларында

**Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советы карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлегенең 25 июнь, 2018 ел, 93 нче карары тарафыннан расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә түбәндәге эчтәлектәге үзгәреш кертергә.

12.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12.3. Россия Федерациясе норматив хокук актларында билгеләнгән исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасын башкаручы граждан муниципаль хезмәттән киткәннән соң ике ел дәвамында хезмәт килешүе шартларында оешмада вазыйфа башкарырга һәм (яки) әлеге оешмада ай дәвамында гражданлык-хокукый килешү шартларында йөз мең сумлыктан артык бәяле эш (әлеге оешмада хезмәтләр күрсәтергә) башкарырга хокуклы, әгәр муниципаль хезмәткәрнең хезмәттә үз-үзен тотуына һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга таләпләрне үтәү буенча тиешле комиссия ризалыгы белән әлеге оешманың аерым муниципаль (административ) функцияләре муниципаль хезмәткәрнең хезмәт вазыйфасына керсә".

26.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"26.3. "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында"гы 2 март, 2007 ел, 25-ФЗ санлы Федераль законның 14.1, 15 һәм 27 нче маддәләрендә каралган шелтә белдерүләр Татарстан Республикасының норматив-хокук актлары һәм (яки) муниципаль хокук актлары тарафыннан билгеләнгән тәртиптә яллаучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннан кулланыла:

1) коррупция һәм башка хокук бозуларны булдырмау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсе тарафыннан үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре турында доклад нигезендә;

2) әгәр тикшерү нәтиҗәләре турындагы доклад комиссиягә җибәрелсә, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәттә үз-үзләрен тотышына таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссия тәкъдимнәре нигезендә;

3) коррупция һәм коррупцион хокук бозулар турында башка хокук бозуларны булдырмау буенча тиешле муниципаль орган кадрлар хезмәте бүлекчәсе доклады (анда аның нинди хәлләрдә кылынуы бәян ителә) һәм муниципаль хезмәткәрнең аның ризалыгыннан башка гына язмача аңлатмасы нигезендә һәм ул коррупцион хокук бозуларны кылу фактын тану шартларында (ышанычны югалтуы сәбәпле эштән азат итү рәвешендә шелтә куллланудан башка);

4) муниципаль хезмәткәрнең аңлатмалары нигезендә;

5) башка материаллар нигезендә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталында җирлек сайтында бастырырга һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советы бинасында махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземдә калдырам.

**Алексеевск муниципаль районы**
**Зур Тигәнәле авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **С.Ж.Әхмәтҗанов**

СОВЕТ БОЛЬШЕТИГАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ